КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 апрель

г.Казань

№ 236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2020 ел, 25 февраль, 141 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы, 2020 ел, 10 ноябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 15 июнь, 455 нче; 2021 ел, 19 июль, 587 нче; 2022 ел, 22 февраль, 153 нче; 2022 ел, 21 апрель, 380 нче; 2022 ел, 4 июль, 624 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1128 нче; 2022 ел, 18 ноябрь, 1236 нчы; 2022 ел, 26 декабрь, 1418 нче; 2023 ел, 19 апрель, 498 нче, 2023 ел, 26 июль, 887 нче, 2024 ел, 20 март, 169 нчы, 2024 ел, 13 июнь, 423 нче, 2024 ел, 23 ноябрь, 1046 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 3.3.6$^2$ пунктча өстәргә:

«3.3.6$^2$. Татарстан Республикасы милкенә әйләндерелгән конфискацияләнгән мөлкәт белән, исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган административ хокук бозу коралы яисә предметы булган конфискацияләнгән мөлкәт белән эш итә.»;

3.3.30 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.30. Дәүләт унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеген мониторинглауны һәм анализлауны, милекченең вәкаләтләре Татарстан Республикасы милкендә булган акцияләренең (устав капиталларындагы өлешләрнең) 50 проценттан артыгы башкарма хакимиятнең башка республика органнарына һәм хуҗалык җәмгыятьләренә тапшырылган дәүләт предприятиеләреннән тыш, шул исәптән хуҗалык алып бару хокукында дәүләт предприятиеләренә беркетелгән һәм күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларына кертелгән мөлкәтне саклап калу максатларында кызыксынган республика башкарма хакимият органнары, салым органнары катнашында ведомствоара баланс комиссияләре уздыру юлы белән гамәлгә ашыра.»;

3.3.36 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Законнарда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне күчереп алуны килештерә, гамәлгә ашыра.»;

3.3.38 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.38. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карар проектын килештерә.»;

3.3.41 пунктчада:

беренче абзацта «акционер» сүзен «хуҗалык» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «акционер» сүзен «хуҗалык» сүзенә алмаштырырга;

3.3.42 пунктчада «акционер» сүзен «хуҗалык» сүзенә алмаштырырга;

3.3.44 пунктчада:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Законнар таләпләре нигезендә хосусыйлаштырыла торган предприятиеләрнең устав капиталы зурлыгын билгели.»;

икенче абзацта «, бәяләү бәясен раслый һәм хосусыйлаштырыла торган предприятиеләрнең устав капиталы күләмен билгели» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.48 пунктчаның беренче абзацында «акционер» сүзен «хуҗалык» сүзенә алмаштырырга;

3.3.50 пунктчада:

беренче абзацта «акционерлык җәмгыятьләре (хуҗалык җәмгыятьләре), акцияләр (устав капиталындагы өлешләр)» сүзләрен «хуҗалык җәмгыятьләре, акцияләр (устав капиталларындагы өлешләр)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Законнарда билгеләнгән очракларда акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең аларны башкаруда кызыксыну булган эре килешүләрен һәм килешүләрен хуплау турында карар кабул итә.»;

3.3.51 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.51. 100 процент акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләрендә акционерларның (катнашучыларның) гомуми җыелышы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.»;

3.3.62 пунктчасында «акционерлык җәмгыятьләренең Татарстан Республикасы милкендәге акцияләре буенча (башка хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталындагы өлешләр буенча керемнәр)» сүзләрен «хуҗалык җәмгыятьләренең Татарстан республикасы милкендәге акцияләре (устав капиталларындагы өлешләр) буенча чиста табыш» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.63 пунктчаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.63. Татарстан Республикасы бюджетына дәүләт предприятиеләренең чиста табышы өлешен күчерүне оештыра.»;

3.3.72 пунктчада «акционерлык җәмгыятьләре (хуҗалык җәмгыятьләре), акцияләр (өлешләр, кертемнәр)» сүзләрен «(контроль) хуҗалык җәмгыятьләре, акцияләр (өлешләр)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.74 пунктчада:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре)Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре мәнфәгатьләре;»;

алтынчы абзацта «устав (җыелма) капиталларында өлеше (кертеме) булган» сүзләрен «акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) милектә булган» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

3.3.76 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.81^2$ пунктча өстәргә:

«$3.3.81^2$. Татарстан Республикасы территориясендә төбәк әһәмиятендәге комплекслы кадастр эшләре заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.83^2$ пунктча өстәргә:

«$3.3.83^2$. Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкармаган башка коммерциягә карамаган оешмаларга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүне гамәлгә ашыра.»

4.1 пунктта:

4.1.3 пунктчада «Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләп кую» сүзләрен «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре вәкилләрен билгеләп кую (сайлауга чыгару)» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.4. Акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре акционерларының (катнашучыларының) гомуми җыелышларында көн тәртибенә законда билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәрне җибәрергә, аларны үткәрүне тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.»;

4.2 пунктта «устав капиталында кертеме булган» сүзләрен «акцияләре (устав капиталларындагы өлешләре) милектә булган хуҗалык җәмгыятьләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин